Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авыл Советы

# КАРАРЫ

23 апрель 2024 ел №92

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Советының 2021 елның 29 октябрендәге 24 номерлы «Ямаши авылы җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2024 елның 30 январендәге 02-08-01/34 номерлы протестын караганнан соң

Ямаши авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Советының 2021 елның 29 октябрендәге24 номерлы «Ямаши авылы җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына ( Әлмәт муниципаль районы авыл Советының 2022 елның 25 февралендәге 36 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 47 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 71 номерлы, 2023 елның 26 октябрендәге 80 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлек 8 статья 11 пункт 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Бюджет йөкләмәләрен яки бюджет ассигнованиеләренең җиткерелгән лимитлары чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм үти, элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә;»

1.2. 12 статья 1 бүлекнең өченче абзацы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның резерв фонды күләме җирлек бюджеты турындагы карар нигезендә җирлек Советы белән билгеләнә.».

2. 1 бүлек 19.1 статья 3 пункт, 19.2 статья 3 пунктның 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр (бюджет турында карар нигезендә муниципаль гарантияләр бирү өлешендә) гамәлдә булуын туктатып торырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы Ямаши авылы, Совет урамы, 4 нче йорт; Рокашево авылы, Үзәк урам, 1 нче йорт; Красная Горка авылы, Тихая Аллея урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның 2 пункты рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ямаши
авыл җирлеге Башлыгы А.А. Андревкина